
Р. К. Шәехова



# Авазларны уйнатып

## **Методик кулланма**

Мәктәпкә әзерлек төркемендә эшләүче
тәрбиячеләр өчен

Казан
ХӨТЕР
2011

УДК 512.145
ББК 81.2Тат
Ш11

Рецензентлар:
**М. Г. Мозаффарова —**
*ТР Мәгарифне үстерү институтының мәгарифтә милли проблемалар лабораториясе мөдире, педагогика фәннәре кандидаты*
**Г. Х. Кәримова —**
*Казан шәһәре 50 нче балалар бакчасының югары квалификацион категорияле татар теленә өйрәтү тәрбиячесе*

Тышлык рәссамы ***Юлия Щетинкина***

**Шәехова, Р.К.**
Ш11 Авазларны уйнатып : методик кулланма: мәктәпкә әзерлек төркемендә эшләүче тәрбиячеләр өчен. – Казан : Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2011.– 44 б.
ISBN 978-5-94113-372-7

УДК 512.145
ББК 81.2Тат

Тәкъдим ителгән методик кулланмада мәктәпкә әзерлек төркемендә эшләүче тәрбиячеләр өчен балаларны уку-язу нигезләрен үзләштерүгә әзерләү буенча шөгыльләр системасы күрсәтелгән.

ISBN 978-5-94113-372-7

© Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2011
© Шәехова Р. К., 2011

НЕТЕР Р.Н.

## Аңлатма язуы

«Мәктәпкә әзерлек программасы»ның «Туган телебезне өйрәнәбез» бүлеге баланың сүз байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үсешен, аның эчтәлеген тасвирлап һәм хикәяләп сөйләү, иҗади фикер йөртү һәм фикерен аңлатып бирә белү күнекмәсе үсешен тәэмин итү эшчәнлеге билгели.

Әлеге бүлектә шөгыль әзерләү һәм үткәрү барышында балаларны грамоталылык нигезләрен үзләштерү эшенә актив әзерләү алып барыла. Педагог максатчан рәвештә балаларны тәкъдим ителгән һәр сүзгә аваз анализы ясарга: сузык авазларны, калын һәм нечкә әйтелешле тартык авазларны аера белергә, теге яки бу сүзне барлыкка китергән авазлар рәтендә ориентлашырга, бирелгән модельләргә туры китереп сүзләр сайларга өйрәтә.

Сүзләргә аваз анализы – Программа таләп иткән уку эшчәнлегенең берничә адымын үз эченә алган бик катлаулы бурыч. Әлеге бурычны эффектив хәл итүдә «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып» дип аталган эш дәфтәрләре ярдәмгә киләчәк.

Сүзләргә аваз анализы ясау процессын адымлап карыйк.

***Беренче адым: авазларны әйтә-әйтә, күрсәткеч таякчыкны сүзнең схемасы буенча йөртү.*** Әле укырга өйрәнмәгән бала өчен бу гамәл үтә катлаулы. Авазны әйтү һәм күрсәткеч таякчыкны салмак кына хәрәкәтләндерү процессларының тәңгәллеген тәэмин итүдә тәрбияченең (укытучының) роле аеруча зур. Такта янында эшләүче баланың кулыннан тотып, күрсәткеч таякчыкны хәрәкәтләндерүдә ярдәм итү зарур. Шушы рухта ярдәмләшеп эшләү өчен, такта янына мөмкин кадәр күбрәк баланы чакыру кирәк, һәм бу этапта анализ өчен 2–3 аваздан гына торган сүзләр бирү мөһим.

***Икенче адым: сүздәге авазларны интонация белән аерып, бер-бер артлы әйтү.*** Бу гамәл бала өчен гадәти эш түгел, шуңа күрә авыр. *(Сер түгел, һәр тәрбияче дә билгеле бер авазны гына интонация белән оста итеп аерып күрсәтә алмый.)*

***Өченче адым: интонация белән аерып алынган авазның үзен генә әйтү.*** Бу да шактый катлаулы бурыч: балалар еш кына сузык авазны интонация белән күрсәткәннән соң да аерып алып әйтә алмыйлар, ә алдагы тартык авазга кушып кына әйтәләр. Шушы киң таралган хатаны булдырмый калу максаты белән «Тере модельләр» уенын куллану тәкъдим ителә.

***Дүртенче адым*** (сүзгә аваз анализы ясауның башлангыч этабында башкарылырга тиешле соңгы адым): ***интонация белән аерып алынган һәм аерым да әйтелгән авазны фишка белән тамгалау.***

Бу чорда балалар гаҗәеп катлаулы гамәл үзләштерәләр – үзләренең артикуляцияләре белән идарә итәргә, сөйләмнәрен күрсәткеч таякчык хәрәкәте белән тәңгәл китерергә өйрәнәләр. Уку эшчәнлегенең әлеге адымын такта янында берничә бала белән кабатлаганнан соң гына, балаларга үзләренең эш дәфтәрләреннән үз күрсәткеч таякчыклары ярдәмендә мөстәкыйль рәвештә «укырга» тәкъдим ителә.

Тәрбияче (укытучы) сөйләме баланың сөйләм үсеше өчен мөһим чыганак, өлге булып тора. Авазларны дөрес әйтү күнекмәсе уңышлы формалашсын өчен, сөйләмдә авазларны һәм аваз кушылмаларын ачык, аңлаешлы әйтү зарур. Педагог сүзләргә аваз анализы ясарга гына өйрәтеп калмый, ә балаларның диалогик һәм монологик сөйләмнәре формалашуга да нигез сала. Бу нәтиҗәлелек педагогның баланы тыңлый һәм ишетә белүенә, фикерен әйтергә ярдәм итеп, төгәлрәк һәм урынлырак сүзләрне, гыйбарәләрне вакытында әйтеп җибәрә белүенә дә бәйле.

Мәгълүм булганча, сөйләмнең төрле стильләре телнең лексик, грамматик, фонологик (бер үк фразаның төрле интонация белән әйтелүе) ***синонимлык*** мөмкинлекләренә дә бәйле. Балалар синонимнарны никадәр еш ишетсәләр һәм кулланадар, аларның сөйләмнәре шулкадәр бай һәм сәнгатьчә яңгырашлы булачак.

Педагог тарафыннан көндәлек аралашуда, уен ситуацияләрендә, шулай ук төрле шөгыльләр барышында һәр баланың сүз байлыгы ачыклануы һәм активлаштырылуы зарур. Моның өчен махсус дидактик уеннар һәм күнегүләрнең гамәлгә куелуы мөһим. Бу очракта «Кем башкача әйтер?», «Кем күбрәк атар?», «Кем тулырак сөйләр?», «Кем киресен әйтер?» кебек күнегүләр аеруча эффектив булачак.

Мәктәпкәчә әзерлек чорында балаларның кечкенә күләмле текстларны бәйләнешле һәм эзлекле итеп сөйли белү күнекмәләрен камилләштерү дәвам итә. Бу чорда Ф.Йосыпов, З.Камалова, Р.Борһановаларның «Гөлбакча» («Мәгариф», 1990) китабына кертелгән хикәяләр һәм әкиятләрне куллану максатка ярашлы булыр. Бу очракта әсәрне башта педагог укый. Аннан соң, сюжетны истә калдыру гына түгел, ә логик сөйләм формалаштыру бурычын да хәл итү йөзеннән, әсәр сюжеты буенча әңгәмә оештырыла. Шуңа күрә әңгәмә, һичшиксез, әсәрдә тасвирланган вакыйгаларны текстка якын һәм мавыктыргыч итеп сөйләп бирү, автор куйган сорауга бергәләп җавап эзләү ихтыяҗы уята торган сорау һәм биремнәр белән баетылырга тиеш.

Сөйләмнең синтаксик ягын камилләштерү өчен, баланы үз фикерен дәлилле аңлата белергә өйрәтү мөһим. Моның өчен әзерлек барышында, махсус рәвештә, дәлилле фикер, инандыру таләп ителгән ситуацияләр тудыру кирәк.

Предмет турында сөйләгәндә, алты яшьлек бала аның төсен, үлчәмен һәм башка үзенчәлекләрен атый. Бу исә аның сөйләменең тиңдәш кисәкләр белән баетылуына китерә. Менә шундый мизгелләрдә бала сөйләменең матурлыгын – аңа башкаларның да игътибарын җәлеп итеп, мактап алу *(«...тыңлагыз әле, төлке турында Камил ничек кызыклы, матур итеп сөйләде: матур, шаян...»)* урынлы булыр.

Мәктәпкә әзерлек чорында балалар кисәкләргә бүленгән рәсемнәр буенча сюжет төзиләр. Әлбәттә, андый рәсемнәрне балалар рәхәтләнеп өйрәнә. Рәсемнәрне билгеле бер эзлеклелектә зур мавыгу белән «җыялар» һәм үз гамәлләрен аңлатып та бирә алалар. Аларның сөйләмендә җәенке җөмләләр киң кулланылышка керә. Сюжетлы рәсемнәр балаларда иҗади эшчәнлек ихтыяҗы тудыра (хикәяләр төзү) һәм формалаштыра, иҗади фикерләүләрен һәм образлы күзаллауларын активлаштыра. Максатка ярашлы сюжетлы рәсемнәрне Н.Виноградованың «Придумай и расскажи» дип аталган әсбабыннан алырга була.

«Туган телне өйрәнәбез» бүлегенә атнага 1–2 сәгать исәбеннән 64 шөгыль каралган. Шөгыльләрнең дәвамлылыгы 30 минуттан артмаска тиеш. Әлеге бүлектә төп игътибар комплекслы шөгыльләргә бирелә. Аларда берничә дидактик бурыч (белем һәм күнекмәләр системага салына, иҗади сәләт үсеше тәэмин ителә) берьюлы гамәлгә ашырыла.

Мәктәпкәчә тәрбиянең гуманистик концепциясе кысаларында баланың шәхес буларак формалашуына, уку һәм укудан тыш эшчәнлектә активлык үсешенә максималь йогынты ясау өчен җирлек тудырылу зарур. Программа таләп иткән бурычларның кайсыларын – шөгыльләрдә, кайсыларын мөстәкыйль эшчәнлектә хәл итү уңышлы, кайчан һәм нинди шартларда кабатлауның кулай булуын педагогка шәхси тәҗрибәсе, иҗади сәләте һәм укыту-методик әдәбият ярдәмгә киләчәк. Күпьеллык тәҗрибә туган телгә өйрәтү шөгыльләренең инде тотрыклы структурасы барлыгын күрсәтә. Структураның яңа вариантларын эзләү мөмкин, әлбәттә; ә инде аларны гамәлгә кую фәкать максатка ярашлылык принцибы нигезендә генә була ала.

**Автор**

## Мәктәпкә әзерлек төркемендә эшләүче тәрбиячеләр (укытучылар) өчен технологик карта

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Авазны сүздән интонация белән аерып алу. | Педагог тарафыннан интонация белән аерып алынган авазларны ишетергә өйрәтү.<br>Бирелгән аваз белән сүзләрне әйтү күнекмәләрен булдыру.<br>Балаларның тәрбияче сөйләме белән кызыксынуларын хуплау. Тәрбияче булышлыгы белән уеннарда диалогик аралашуны җайга салу.<br>*Шар, шарф, шалкан, кош, шикәр, чыршы, кишер, пирожный, жираф* сүзләренә аваз анализы ясау. | Балаларны уку әсбабы белән таныштыру.<br>«Күзгә парта» уены.<br>Авазларны дөрес әйтергә өйрәнү күнегүләре.<br>Рәсемнәр буенча эш: һәрбер сүздә интонация белән **[ш]** авазын аерып алу.<br>Рәсем буенча тасвирлама текст төзү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 4–5. |
| 2. | **[ш]** авазын сүздән интонация белән аерып алу. | Педагог тарафыннан интонация белән аерып алынган авазларны ишетү күнекмәләрен ныгыту. Авазны сүздән мөстәкыйль аерып алырга өйрәтү (педагог үрнәгендә).<br>«Аваз» төшенчәсен күзаллауны формалаштыру.<br>Балаларның сүз байлыгын активлаштырырга булышлык итү. | Телшомарткыч белән эш.<br>Истә калдыру ситуациясе тудыру; үзләштерелгән **[ш]** авазын ишетү һәм аерып алу күнекмәсен ныгыту.<br>**[ш]** авазы «яшерелгән» рәсемнәр белән эш.<br>«Кайтаваз» уены. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 6–7. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| | | *Каш, машина, шакмак, оекбаш, карандаш, (яшь) кеше; аю, туңдырма, жираф* сүзләренә аваз анализы ясау. | «Ягымлы сүзләр» уены *(песи-пескәй, кәҗә-кәҗәкәй, баш-башкай).* | |
| 3. | Артикуляция һәм яңгырашлары буенча якын торган **[ш]** һәм **[ж]** авазларын чагыштыру. | Сүздән аерым авазны интонация белән аерып алып әйтү күнекмәсен ныгыту.<br>Бирелгән авазны аерып алу, артикуляция һәм яңгырашлары буенча якын торган авазларны чагыштыра белү (терминнарны кулланмыйча гына) күнекмәсен формалаштыру.<br>Балаларның сөйләмен гомумиләштерүче сүзләр (киемнәр, хайваннар, үсемлекләр) белән баету һәм гомумиләштерә белү күнекмәсен булдыру.<br>*Башлык, кош, көнбагыш, кашык, груша; жилет, пирожный, журнал, жираф* сүзләренә аваз анализы ясау. | Җил турында шигъри табышмак әйтү.<br>Рәсемнәр буенча **[ж]** авазы ишетелгән сүзләрне әйтү.<br>Рәсемнәр буенча **[ш]** авазы ишетелгән сүзләрне әйтү.<br>«Кем күбрәк сүз әйтә?» уены (фишкалар ярдәмендә уйнала).<br>Рәсемнәр карау, предметларны функциональ билгеләре буенча классификацияләү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 8–9. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Сүздән **[ж]** һәм **[жь]** авазларын аерып алу. | Сүзне аерым авазны интонация белән аерып алып әйтү күнекмәсен ныгыту.<br>**[ж]** авазын ишетү һәм әйтү күнекмәсен булдыру. Сөйләмдә **[жь]** һәм **[ж]** авазлары булган сүзләрне активлаштыру.<br>Балаларны калын (кырыс) һәм нечкә (ягымлы) әйтелә торган тартык авазларны ишетү һәм аларны аера белү күнекмәсен булдыру.<br>Сөйләмдә антоним сүзләрне актив куллануларына булышлык итү.<br>*Җиләк, җилкән, җимлек, җимешләр, кәҗә, җир, җанвар, тажҗ, җомга* сүзләренә аваз анализы ясау. | «Зур һәм кечкенә конгызлар» уен-күнегүе.<br>Авазларны дөрес әйтергә өйрәнү күнегүләре.<br>«Кайтаваз» уены.<br>Рәсемнәр буенча «ягымлы» **[жь]** авазы кергән сүзләрне әйтү.<br>«Киресен әйт» уены *(авыр – җиңел, җайсыз – җайлы, салкын – җылы).* | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 10–11. |
| 5. | Сүздән **[з]** һәм **[зь]** авазларын аерып алу. | Сүзне аерым авазны интонация белән аерып алып әйтү күнекмәсен ныгыту.<br>Балаларның калын (кырыс) һәм нечкә (ягымлы) әйтелә торган тартык авазларны ишетү һәм бербереннән аера белү күнекмәләрен үстерү. | «Зур һәм кечкенә черкиләр» уен-күнегүе.<br>Авазларны дөрес әйтергә өйрәнү күнегүләре.<br>Рәсемнәр буенча «кырыс» **[з]** авазы кергән сүзләрне әйтү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 12–13. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| | | Сөйләмдә **[зь]** һәм **[з]** авазлары булган сүзләрне активлаштыру.<br>Балаларда авазларның төрле яңгырашын белергә теләү хисе уяту һәм игътибарлы булырга өйрәтү.<br>*Коңгыз, каз, карбыз, ваза, зебра, тәрәзә, көзге, кәрзин, күзлек* сүзләренә аваз анализы ясау. | Рәсемнәр буенча «ягымлы» **[зь]** авазы кергән сүзләрне әйтү.<br>«Умарталык» рольле уены (умартачы ролендә – педагог, бал кортлары ролендә – балалар). | |
| 6. | Сүздән **[з]** һәм **[зь]**; **[ж]** һәм **[жь]** авазларын аерып алу. | Шигъри юллардан аерым авазны интонация белән аерып алып әйтү күнекмәсен булдыру.<br>Балаларның артикуляция һәм яңгырашлары буенча якын торган авазларны чагыштыра белү, калын (кырыс) һәм нечкә (ягымлы) әйтелә торган тартык авазларны ишетү һәм бер-береннән аера белү күнекмәләрен үстерү.<br>Сөйләмдә **[зь]** һәм **[з]**; **[ж]** һәм **[жь]** авазлары булган сүзләрне активлаштыру.<br>*Казан, роза, бозау, зебра, күзлек, җиләк, җимлек, таҗ, божра* сүзләренә аваз анализы ясау. Биремнәрне мөстәкыйль үтәргә омтылу өчен җирлек булдыру. | Шигъри юллар тыңлау.<br>Шигырьдәге **[ж]** авазлары ишетелгән сүзләрне әйтү.<br>Шигырьдәге **[з]** авазлары ишетелгән сүзләрне әйтү.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Игътибарлы бул!» уены.<br>Рәсем буенча тасвирлама текст төзү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 14–15. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Калын һәм нечкә әйтелә торган тартык **[с]** һәм **[сь]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен булдыру.<br>Тартык авазның калын яки нечкә әйтелешле булуын билгеләү ысулын үзләштерү.<br>Танып белү эшчәнлегендә үзләштерелгән алгоритмны куллану күнекмәсен формалаштыру.<br>*Сарык, сабын, сыер, сарымсак, песи, сөлге, кәбестә, сәгать* сүзләренә аваз анализы ясау. | «Каз һәм каз бәбкәсе» уены.<br>Рәсемнәр белән эш: исемнәрендә «кырыс» **[с]** һәм «ягымлы» **[сь]** авазлары ишетелгән предметларны атау.<br>«Кырыс» һәм «ягымлы» малайлар» уен-күнегүе.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>Иллюстрацияләр буенча «кырыс» һәм «ягымлы» малайлар турында тасвирлама-текст төзү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 16–17. |
| 8. | **[л]** һәм **[ль]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | «Кырыс» һәм «ягымлы» аваз төшенчәләрен ныгыту.<br>Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм, авазның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү.<br>Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү. | Рәсемнәрдәге хайван һәм башка җан ияләренең исемнәрен әйтү. Предметларны функциональ билгеләре буенча классификацияләү.<br>Хайваннар турында әңгәмә үткәрү.<br>Рәсемнәр белән эш: сүзләрдән интонация белән **[л]** һәм **[ль]** аваз- | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 18–19. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| | | Күмәк сөйләшүдә катнашу теләге уяту: сораулар бирү; җавапларны дәлилли белү, куелган сорауларга җавап бирү күнекмәләрен үстерү.<br>Балаларда хайваннар дөньясына карата кызыксыну уяту.<br>*Алма, шалкан, акула, болан, крокодил, елан, балык, фил, төлке, дельфин, күбәләк, леопард, че探* сүзләренә аваз анализы ясау. | ларын аерып алу буенча күнегү.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Кайтаваз» уены. | |
| 9. | **[м]** һәм **[мь]** авазларын ишетү һәм бер-береннән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү.<br>Балаларның үзләренә якын булган темага, сөйләмнәрендә үткәннәрнең тәэсирен чагылдырып сөйли белү күнекмәләрен камилләштерү.<br>*Мәк, маймыл, муенса, сарымсак, йомгак, алма, миләш, мәче, гөмбә* сүзләренә аваз анализы ясау. | «Мырауҗан» хикәясен тыңлау.<br>Монологик сөйләм күнекмәсе. (Балалар үзләре яраткан хайван турында сөйлиләр.)<br>Хикәядәге сүздән интонация белән **[м]** һәм **[мь]** авазларын аерып алу буенча күнегүләр.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Кем күбрәк сүз әйтә?» уены. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 20–21. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 10. | **[н]** һәм **[нь]; [ң]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү.<br>**[ң]** авазының үзенчәлеге белән таныштыру.<br>Бирелгән авазга сүзләр уйлап әйтү күнекмәләрен ныгыту. Аралашу, игътибар белән тыңлау, ишетү, иптәшләренең җавабы белән килешү яки килешмәүләрен дустанә әйтеп бирә белү күнекмәсен формалаштыру.<br>*Чана, нарат, гармун, тиен, имән, инә, кыңгырау, яңгыр, уңыш, таң, моң, дуңгыз, бәрәңге, чаңгы* сүзләренә аваз анализы ясау. | Шигырь тыңлау.<br>Интонация белән сүздән **[н]** һәм **[нь]** авазларын аерып алуга күнегү.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Кайтаваз» уены.<br>«Кем күбрәк сүз әйтә?» уены. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 22–23. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 11. | **[р]** һәм **[рь]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү<br>**[р]** авазын камил әйтү күнекмәсен булдыру.<br>Сүзләрнең әйтелешләре ягыннан охшашлыгын, аермасын таба белү күнекмәләрен булдыру.<br>Сүзләргә аваз анализы ясау күнекмәсен үстерү.<br>*Сарык, сыер, арыслан, бүре, керпе, көнгерә* сүзләренә аваз анализы ясау. | «Цирк аренасында юлбарыслар» рольле уены.<br>Авазларны дөрес әйтергә өйрәнү күнегүләре.<br>«Исемендә **[р]** авазы бармы?» уены.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Нәрсә белән охшаш, нәрсә белән аерыла?» уены *(сарык – сыер – арыслан; бүре – керпе – көнгерә).* | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 24–25. |
| 12. | **[к]** һәм **[кь]**; **[къ]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү. | Р. Миңнуллинның «К»-лар тулган бакчага» шигырен тыңлау.<br>Шигырьдән **[къ]** авазы кергән сүзләрне сайлап алып, **[къ]** авазын интонация белән сүздән аерып алуга күнегү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 26–27. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| | | Уку эшчәнлеге компоненты булган үз-үзеңә контроль ясый белү күнекмәсен булдыру.<br>Сүзләргә аваз анализы ясау күнекмәсен үстерү.<br>*Курчак, бака, тавык, кишер, акча, көзге, тәлинкә, күбәләк, күлмәк* сүзләренә аваз анализы ясау. | «Шигырьдәге **[к]** һәм **[къ]** авазлары кергән сүзләрне табып әйтү.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Кайтаваз» уены. | |
| 13. | **[п]** һәм **[пь]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү.<br>Шигырьне сәнгатьле итеп укуларына ирешү.<br>Чагыштыра белү, игътибарлы булу кебек сыйфатлар үсешен тәэмин итү.<br>*Помидор, песнәк, чыпчык, китап, туп, пәрәмәч, пәлтә, ипи*, *җеп* сүзләренә аваз анализы ясау. | Песи турында телшомарткыч өйрәнү.<br>«Песи һәм тычкан нәрсә белән охшаш, нәрсә белән аерыла?» уен-биреме.<br>«Шигырьдәге «кырыс» **[п]**, ягымлы **[пь]** авазы кергән сүзләрне табып әйт» уен-биреме.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Кайтаваз» уены. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 28–29. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 14. | **[в]** һәм **[вь]; [w]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү.<br>Татар теленә хас булган **[w]** авазының үзенчәлеге белән таныштыру.<br>*Ваза, слива, виноград, велосипед, тавык, кавын, савыт, самавыр, хәлвә* сүзләренә аваз анализы ясау. | Шигъри юллар тыңлау. «Шигырьдәге «кырыс» **[в]** һәм «ягымлы» **[вь]** авазы кергән сүзләрне әйт» уен-күнегүе.<br>Дидактик материал белән эшләү.<br>**[w]** авазы кергән сүзләр белән «Кайтаваз» уены.<br>«Дусларга үз рәсемнәрен табарга булыш!» уен-күнегүе. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 30–31. |
| 15. | **[г]** һәм **[гъ];** **[гъ]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү.<br>Татар теленә хас булган **[гъ]** авазының үзенчәлеге белән таныштыру. | Интонация белән сүздән беренче авазны аерып алып, аны башка авазлардан аерып әйтеп, рәсемнәрдә бирелгән предметларның исемнәрен әйтү.<br>Схемадагы калын (нечкә) әйтелешле тартык авазларны зәңгәр (яшел) карандаш белән буяу. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 32–33. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| | | Сүзнең беренче авазын аерып ала белү күнекмәләрен үстерү.<br>*Лимон, роза, ромашка, кит, кишер, машина, маймыл, пәлтә, пәрәмәч; гном, гитара, гармун, сәгать, бәрәңге, сөлге, күгәрчен, гөмбә, көнгерә; карга, багана, таган* сүзләренә аваз анализы ясау. | «Шундый ук аваздан башланган сүз әйт» уенбиреме.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Кайтаваз» уены. | |
| 16. | **[х]** һәм **[хь]**; **[h]** авазларын ишетү һәм сүздән интонация белән аерып алу. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү.<br>Татар теленә генә хас булган **[h]** авазының үзенчәлеге белән таныштыру.<br>Туган телнең үзенчәлекләрен күбрәк белү теләге, кызыксыну уяту.<br>*Халат, хат, шахмат, хәлвә, хәреф, хөрмә, һәйкәл, һөнәр, шәһәр, һава, Илһам* сүзләренә аваз анализы ясау. | Р. Миңнуллинның «Хат» шигырен тыңлау.<br>«Шигырьдәге «кырыс» **[х]** һәм «ягымлы» **[хь]** авазы кергән сүзләрне әйтү.<br>Мөстәкыйль эш: «Рәсемнәрне «малайлар портреты» белән тоташтыр».<br>«**[h]** авазы кергән сүзләр белән «Кайтаваз» уены.<br>«**[h]** авазы кергән сүзләр уйлап әйт» уен-ярышы. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 34–35. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 17. | Сүзнең беренче авазын аерып ала белү күнекмәләрен ныгыту. | Балаларда сүздән авазны интонация белән аерып алу һәм аның калынлыгын-нечкәлеген саклап калып, башка авазлардан аерып әйтү күнекмәсен үстерү. Тартык авазның калын һәм нечкә әйтелешен ачыклау ысулын куллану күнекмәсен камилләштерү.<br>Түбәндәге план-схема буенча табышмаклар төзи белү күнекмәсен булдыру: «Нәрсәгә охшаган? Нәрсә белән аерыла?»<br>Балаларда иҗади фикерләү күнекмәсен булдыру.<br>*Бака – бәрән, лампа – лимон, рам – рәшәткә, җанвар – җиләк, флаг – фил, сабын – себерке, машина – мәче, карбыз – күгәрчен, груша – герб, ваза – виноград* сүзләренә аваз анализы ясау. | «Рәсемдәге сүзләрнең беренче авазын әйт» биреме.<br>«Парын тап һәм дөрес итеп буя» уен-биреме.<br>«Туганын тап» уены.<br>«Дөрес әйт» уены.<br>Табышмак төзү һәм җавабының рәсемен ясау. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 36–37. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| 18. | Сүз схемасы төзү. | Авазларны шартлы билгеләр белән күрсәтеп, сүзнең схемасын төзү күнекмәсен булдыру.<br>Сүзнең беренче авазын аерып ала белү күнекмәләрен ныгыту. Уку эшчәнлеге компоненты булган үзконтроль, үзбәя күнекмәләрен булдыру.<br>Әңгәмәдә катнашу теләге һәм үз-үзенә ышаныч уяту өчен җирлек булдыру.<br>*Аю, агач, ат, автобус, учак, уенчык, урындык, укучы* сүзләренә аваз анализы ясау. | Иллюстрация эчтәлеге буенча әңгәмә.<br>«Рәсем буенча хикәянең башын уйла» биреме.<br>*Ау* сүзендә **[а]** һәм **[у]** авазларын интонация белән аерып алу. *«Ау»* сүзен схемада күрсәтү.<br>Эш дәфтәрендә мөстәкыйль эшләү.<br>«Кем күбрәк сүз әйтә?» уены. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 38–39. |
| 19. | Аваз модельләрен кулланып, сүзләргә аваз анализы ясау. | Сүзгә аваз анализы ясау ысулын аерып алу. «Схема», «модель» төшенчәләрен үзләштерү.<br>*Ат* һәм *ут* сүзләренә аваз анализы ясау.<br>Чагыштыра белү, игътибарлы булу кебек сыйфатлар үсешен тәэмин итү. | *Ат* сүзенә аваз анализы ясау.<br>«Тере модельләр» уены.<br>*Ут* сүзенә аваз анализы ясау.<br>*Ат* һәм *ут* сүзләрен чагыштыру.<br>5. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 40–41. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 20. | Сүзләрнең төзелешен һәм мәгънәсен аңлату. | Схеманы «укып», сүзләрне чагыштыру. «Схема», «модель» төшенчәләрен ныгыту.<br>Бирелгән аваз кергән сүзләр сайлап алу күнекмәләрен булдыру.<br>*Туп* һәм *тун* сүзләренә аваз анализы ясау, аларны чагыштыру.<br>«Ул нинди? – Шундый ук, нәрсә?» схемасы буенча табышмаклар төзү. Балаларда иҗади фикерләү күнекмәсен булдыру. | *Туп* сүзенә аваз анализы ясау.<br>«Тере модельләр» уены.<br>Схеманы укып, *туп* һәм *тун* сүзләрен чагыштыру.<br>«Кем күбрәк сүз әйтә?» уен-ярышы.<br>Үсемлекләр турында табышмаклар төзү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 42–43. |
| 21. | Сүзләрдә авазның урынын билгеләү. | Сүзгә аваз анализы ясау күнекмәсен камилләштерү, модель буенча сүзләрне чагыштыру.<br>Сүздә авазның урынын билгеләргә өйрәтү.<br>Бирелгән сүзгә тамырдаш сүзләр сайлау аша сүз байлыгын арттыру. Бәйләнешле сөйләм үстерү.<br>Яңа сүзләрне *(орлык, үсенте, чәчәк бөресе, чәчәк)* сөйләмдә активлаштыру.<br>*Мәк* сүзенә аваз анализы ясау. | *Мәк* сүзенә аваз анализы ясау.<br>*Мәк* сүзе белән «Тере модельләр» уены.<br>«Башта нәрсә, аннан соң нәрсә?» дидактик уены.<br>«Охшаш сүзләр уйлап әйт» дидактик уены (мәк – мәкле, чәчәк – чәчәкле...).<br>«Кем күбрәк сүз әйтә?» уен-ярышы.<br>«Сез beләсезме, миләш – ул...». Яңа мәгълүмат ишетеп кабул итү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 44. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 22. | Татар теленең үзенчәлекле авазлары (**[ү]**, **[ә]**) кергән сүзләргә аваз анализы ясау. | Сүзгә аваз анализы ясау күнекмәсен камилләштерү.<br>Сүзне әйткәндә бирелгән авазны аерып алу, сүзләрдә бертөрле авазларны табып әйтү күнекмәләрен ныгыту.<br>Балаларда бирелгән мәгълүматка карата кызыксыну һәм игътибарлылык булдыру.<br>*Мүк* һәм *мәк* сүзләренә аваз анализы ясау, аларны чагыштыру. | «Сез беләсезме, мүк – ул...». Яңа мәгълүмат ишетеп кабул итү.<br>*Мүк* сүзенә аваз анализы ясау.<br>**[ү]** авазы кергән сүзләр уйлап әйтү.<br>*Мүк* һәм *мәк* сүзләрен чагыштыру.<br>«Сүзне уйлап әйт» уены. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 45–46. |
| 23. | Күп мәгънәле сүзләр төшенчәсе белән таныштыру. | Сүзгә аваз анализы ясау күнекмәсен камилләштерү.<br>Сүздән беренче һәм соңгы авазларны аерып алуга күнегүләр бирү.<br>«Күп мәгънәле сүзләр» төшенчәсе белән таныштыру.<br>Игътибарлылык һәм иҗади фикер үсеше өчен җирлек тудыру. | *Күл* сүзенә аваз анализы ясау.<br>*Мүк* сүзе белән «Тере модельләр» уены.<br>*Күл* һәм *мүк* сүзләрен чагыштыру.<br>«Сүзләр чылбыры» уены.<br>«Сез беләсезме, нинди энәләр була?...». Яңа мәгълүмат ишетеп кабул итү (тегү энәсе, бәйләү энәсе, ылыс-энә, керпе энәсе, кактус энәсе һ.б.). | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 47–48. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 24. | Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрне чагыштыру. | Сүзгә аваз анализы ясау күнекмәсен камилләштерү.<br>Балаларның калын һәм нечкә авазларны парлап әйтә белүләрен ныгыту.<br>Сүзләрне чагыштыра белү күнекмәләрен үстерү.<br>*Сул, кул, күлмәк, сыр, слива, сөт, сок, сохари, салат* сүзләренә аваз анализы ясау. | *Кул* сүзенә аваз анализы ясау.<br>*Кул* сүзе белән «Тере модельләр» уены.<br>*Сул* сүзенә аваз анализы ясау. *Сул* сүзенең мәгънәсен аңлату.<br>*Сул* һәм *кул, кул* һәм *күл, мәк* һәм *күл* сүзләрен чагыштыру.<br>«Кем күбрәк сүз әйтә?» уены. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 49–50. |
| 25. | Нечкә әйтелешле сүзләр белән эш. | Сүзгә аваз анализы ясау күнекмәсен камилләштерү.<br>Нечкә әйтелешле тартык аваздан башланган сүзләр уйлап әйтә белүләрен ныгыту.<br>Балаларның игътибарын, җавап әзерләү тизлеген үстерү; аларда танып белүгә кызыксыну уяту.<br>*Песнәк, җеп, төлке, шикәр, диван, мәк, гитара, бегемот, сәгать, кишер, зебра, чиләк* сүзләренә аваз анализы ясау. | *Күл* сүзенә аваз анализы ясау.<br>*Күл* сүзе белән «Тере модельләр» уены.<br>*Кул* һәм *күл* сүзләрен чагыштыру.<br>«Бу рәсемнәрнең атамаларында нинди охшашлык бар?» биреме.<br>Туп белән уен: «Дөрес әйт». | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 51–52. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 26. | Калын әйтелешле сүзләр белән күнегүләр. | Сүзгә аваз анализы ясау күнекмәсен камилләштерү.<br>Сүзләрне чагыштыра белү күнекмәләрен үстерү.<br>Балаларның игътибарын, җавап әзерләү тизлеген үстерү.<br>*Пычак, кояш, сабын, шарф, балык, тукран, чаңгы, дага, хат, гармун, нарат, маймыл, рам* сүзләренә аваз анализы ясау. | *Тоз* сүзенә аваз анализы ясау.<br>*Көз* сүзенә аваз анализы ясау.<br>*Тоз* һәм *көз* сүзләрен чагыштыру.<br>«Бу рәсемнәрнең атамаларында нинди охшашлык бар?» биреме.<br>Туп белән уен: «Дөрес әйт». | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 53–54. |
| 27. | Сузык авазлар төшенчәсе белән таныштыру. | Сузык авазларның «төсле» билгеләмәсе белән таныштыру.<br>Сүзгә аваз анализы ясарга өйрәтүне дәвам итү, сүздәге сузык авазларны табып әйтү.<br>Мөстәкыйль рәвештә сузык авазны сүздән аерып алуга күнегүләр бирү.<br>Иҗади характердагы уен-биремнәрне үтәү күнекмәләрен үстерү.<br>*Шар (шарф, алма, ручка), мәк (миләш, әтәч, кәбестә), күл (күлмәк, үрдәк, лимон), көз (көнгерә, өстәл, зебра)* сүзләренә аваз анализы ясау. | Дәфтәрләрдә сүзнең аваз төзелеше буенча эш.<br>«Тылсымлы» сузык авазлар турында хикәя тыңлау.<br>*Шар, мәк* сүзләренә аваз анализы ясау.<br>«Сүзләрдәге сузык авазларны тап!» уен-күнегүе.<br>Ребус чишү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 55–56. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| 28. | Сузык авазлар төшенчәсе белән күнегүләр. | Сүзгә аваз анализы ясау күнекмәсен үстерү.<br>Сузык авазларны тартык авазлардан аера белү күнекмәләрен ныгыту.<br>Бер үк авазлардан төзелгән төрле мәгънә белдерә торган сүзләрне урынлы куллану күнекмәсен булдыру.<br>*Бала, үлән, дару, роза, лалә* сүзләренә аваз анализы ясау. | *Бала* сүзенә аваз анализы ясау.<br>«Тылсымлы авазларны без ничек беләбез?» әңгәмәсе.<br>*Бала* сүзе белән «Тере модельләр» уены.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү.<br>«Бала һәм олы кеше нәрсә белән охшаш (охшаш түгел)?» уен-биреме. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 57–58. |
| 29. | Калын һәм нечкә әйтелешле тартык авазлар төшенчәләрен кертү. | «Калын әйтелешле тартык аваз» һәм «нечкә әйтелешле тартык аваз» төшенчәләре белән таныштыру.<br>Калын һәм нечкә әйтелешле тартыкларны төсле фишкалар белән билгеләү.<br>Сүзгә аваз анализы ясау, әйтелгән сүз белән сүзнең авазлар төзелеше схемасының үзара бәйләнешен билгеләү.<br>Балаларда пөхтәлек, игътибарлылык, җаваплылык тәрбияләү. | Схема буенча *лалә* сүзенә аваз анализы ясау. Калын һәм нечкә әйтелешле тартыкларны төсле фишкалар белән билгеләү.<br>*Лалә* сүзенең моделен анализлау.<br>*Зифа* сүзенең моделен анализлау.<br>*Зифа* сүзе белән «Тере модельләр» уены.<br>Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эшләү. | *Шәехова Р.К.* Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып: эш дәфтәре №1. – Казан: Хәтер, 2011. – Б. 59–60. |

| № | Тема | Максат | Эшчәнлек төрләре | Укыту-методик әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| | | *Лалә, Зифа; үтүк, карбыз, кит, скрипка, көнбагыш, пычкы, әтәч, мәче, чия* сүзләренә аваз анализы ясау. | | |
